ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.01.2023 г. Заинск № 19

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы, «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын кушымта нигезендә расларга.

2. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2022 елның 24 февралендәге 98 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

П.А.Байрашев

3-22-73

Юрист

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «19» 01
19 номерлы карары белән
расланган.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын билгели (алга таба - исемлек, баш администратор).

2. Исемлеккә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторларының составын һәм (яисә) вәкаләтләрен үзгәрткәндә;

- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджет керемнәре классификациясенең кодын (керем төрчәсенең кодын) һәм (яисә) код исемен үзгәрткәндә.

3. Исемлеккә үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе боерыгы белән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының керемнәрнең баш администраторлары тәкъдимнәре нигезендә исемлекне раслый торган карарына үзгәрешләр кертмичә гамәлгә ашырыла.

4. Керемнәрнең баш администраторлары, исемлеккә үзгәрешләр кертергә кирәк булган очракта, бу ихтыяҗ барлыкка килгән көннән алып 5 көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны күрсәтеп, Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тиешле тәкъдимнәрне бирәләр:

- исемлеккә үзгәрешләр кертү өчен нигезләр;

- керемнәрнең баш администраторы коды һәм исеме;

- керемнәр төренең (төрчәләренең) коды һәм исеме.

5. Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы:

- мәгълүматны алу датасыннан соң килгән 3 эш көне эчендә аны әлеге тәртипнең 2 һәм 4 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә карый;

- искәрмәләр булмаган очракта, мәгълүмат керү датасыннан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча исемлеккә үзгәрешләр кертә;

- искәрмәләр булган очракта, керемнәрнең баш администраторына, баш тартуга нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, исемлеккә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында язмача хәбәр итә.